«РАСЛЫЙМ»
Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр
____________ Р.Т. Борһанов
«___» ___________ 2020 нче ел

**Төп дәүләт имтиханы (ТДИ) рәвешендә төп гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе**

**ТАРИХ буенча 2020 елгы төп дәүләт имтиханында**

**контроль үлчәү материалларының күрсәтмә варианты**

**“ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ” Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе**

**тарафыннан әзерләнде**

## 1 нче бүлек

*1-14 биремнәргә җавап булып цифр, цифрлар эзлеклелеге яки сүз (сүзтезмә) тора. Җавапларны башта эшнең текстында, аннан соң аларны 1 нче номерлы ҖАВАПЛАР БЛАНКЫНДА бирем номерының уң ягына беренче шакмактан башлап язарга кирәк. Җавабызны буш ара калдырмыйча, өтер һәм башка өстәмә символлар куймыйча язагыз. Һәр цифрны һәм хәрефне үрнәктә күрсәтелгән тәртиптә аерым шакмакларга языгыз. Россия хакимнәренең исемнәрен бары тик хәрефләр белән язарга кирәк (мәсәлән: Николай Икенче).*

1 Вакыйгалар һәм еллар арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килгән элементны сайлап алыгыз.

| ВАКЫЙГАЛАР | ЕЛЛАР |
|---|---|
| А) Боз сугышы | 1) 1242 ел |
| Б) Россиядә крепостнойлык хокукын бетерү | 2) 1380 ел |
| В) патша Алексей Михайловичның Собор уложениесен кабул итү | 3) 1649 ел |
| | 4) 1762 ел |
| | 5) 1861 ел |

Сайлап алынган саннарны таблицадагы тиешле хәрефләр астына языгыз.

Җавап:

| А | Б | В |
|---|---|---|
| | | |

2 Тарихи вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Тарихи вакыйгалар билгеләнгән саннарны таблицага дөрес тәртиптә языгыз.

1) Михаил Романовны патша итеп сайлау
2) Борис Годуновны патша итеп сайлау
3) Икенче җир ополчениесе формалашу
4) Ялган Дмитрийны бәреп төшерү

Җавап:

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |



**Төп дәүләт имтиханы (ТДИ) рәвешендә төп гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе**

**ТАРИХ буенча 2020 елгы төп дәүләт имтиханында контроль үлчәү материалларының күрсәтмә варианты**

**“ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ”**
**Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе**
**тарафыннан әзерләнде**

ТАРИХ буенча төп дәүләт имтиханы

**ТАРИХ буенча 2020 елгы төп дәүләт имтиханында контроль үлчәү материаллларының күрсәтмә вариантына аңлатмалар**

2020 елгы күрсәтмә вариант белән танышканда, аның 2020 ел КҮМ вариантлары ярдәмендә тикшерелергә тиешле эчтәлекнең барлык вариантларын да чагылдырмавын исәпкә алырга кирәк. Предмет эчтәлегенең 2020 елгы имтиханда тикшерелергә мөмкин булган элементлары төп дәүләт имтиханына укучыларны әзерләү дәрәҗәсенең эчтәлеге һәм куелган таләпләр элементының кодификаторында чагылыш тапкан. Ул www.fipi.ru. сайтына урнаштырылган.

Күрсәтмә вариант имтиханда катнашучыларга һәм киң җәмәгатьчелеккә имтихан эшенең структурасы, биремнәрнең саны һәм формасы, шулай ук катлаулылык дәрәҗәсе турында күзаллау булдыру өчен кирәк. Имтихан эшенең күрсәтмә вариантында бирелгән киңәйтелгән җавапны таләп итә торган биремнәрнең үтәлешен бәяләү критерийлары киңәйтелгән җавапларны язуның тулылыгына һәм дөреслегенә куелган таләпләрне күзалларга ярдәм итә.

Әлеге мәгълүматлар имтиханда катнашачак укучыларга 2020 елгы тарих буенча имтихан тапшыруга әзерләнүнең стратегиясен булдырырга ярдәм итә.



**Тарих буенча 2020 елгы төп дәүләт имтиханында контроль үлчәү материалларының күрсәтмә варианты**

**Эшне башкару буенча күрсәтмә**

Имтихан эше 21 биремне үз эченә алган ике өлештән тора. 1 нче бүлеккә кыска җаваплы 14 бирем кергән, 2 нче бүлек киңәйтелгән җаваплы 7 биремнән гыйбарәт.

Тарих буенча имтихан эшен башкаруга 3 сәгать (180 минут) вакыт бирелә.

1-14 нче биремнәргә җаваплар цифрлар, сан эзлеклелеге яки сүз (сүзтезмә) рәвешендә языла. Бу цифрны эш текстында бирелгән җавап урынына языгыз, аннан соң 1 нче номерлы җаваплар бланкына күчереп языгыз.

15-21 нче биремнәргә киңәйтелгән җавап бирергә кирәк. 15–17 биремнәр тарихи чыганакка анализ ясауны, 18-21 биремнәр тарихи материал белән төрле төрдәге эш башкаруны күз алдында тота: сәбәп-максат бәйләнешләрен билгеләү (18), тарихи текстка анализ, андагы хаталарны табу һәм төзәтү (19), тарихи вакыйгаларны һәм күренешләрне чагыштыру (20), тарихи шәхес эшчәнлеге белән бәйле тарихи ситуациягә анализ (21). 15-21 биремнәрнең җаваплары 2 нче номерлы бланкында языла.

Барлык бланклар куе кара паста белән тутырыла. Гельле яки капиллярлы ручка куллану рөхсәт ителә.

Эшне башкарганда, караламадан файдаланырга ярый. **Эшегезне бәяләгәндә, караламадагы, шулай ук контроль бәяләү материаллары текстындагы язмаларыгыз исәпкә алынмаячак.**

Биремнәрне үтәгәндә алган балларыгыз бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җавап бирергә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

Эш тәмамланганнан соң, 1 нче һәм 2 нче бланкларда һәр биремгә җавапның дөрес номеры язылуын тикшерегез.

***Уңышлар телибез!***

гаскәрләрен карау булды. Воеводалар советыннан соң 26 августта рус полклары шәһәрне калдырып Донның югары агымына таба киттеләр".

Җавап: ☐

11 Рәсемне карагыз һәм сорауга җавап бирегез.




Әлеге тәңкә чыгарылган унъеллыкта санап үтелгән вакыйгаларның кайсысы булган?

1) Россиянең Җидеееллык сугышка керүе
2) Югары яшерен совет эшчәнлеге
3) дворяннарга жалованный грамота бастыру
4) Речь Посполитаяны өченче бүлү

Җавап: ☐

12 Схемадагы бушлыкны тутырыгыз.



3 Түбәндәге аңлатмага туры килә торган терминны языгыз.
Петр I тарафыннан кертелгән йөкләмәләр буенча даими Россия армиясенә җыелган хәрбиләр.

Җавап: ____________________.

4 Санап кителгән шәһәрләрнең кайсылары XIII-XIV гасырларда идарә итүнең республика формасына ия булган рус җирләренең административ үзәкләре булып торган? Ике шәһәрне сайлагыз һәм алар күрсәтелгән саннарны таблицага язып куегыз.

1) Рязань
2) Владимир
3) Новгород
4) Псков
5) Киев

Җавап: ☐☐

5 Түбәндә терминнар исемлеге бирелгән. Берсеннән кала, аларның барысы да турыдан-туры 1894-1914 еллар аралыгына карый.
1) октябристлар; 2) кадетлар; 3) стачка; 4) петрашевчылар; 5) петиция.

Әлеге рәттән «төшереп калдырылырга» тиешле терминның тәртип номерын табыгыз һәм языгыз.

Җавап: ☐

6 Дүрт җөмләне укып чыгыгыз. Аның икесе тезислар (дәлилләү таләп итәлә торган нигезләмәләр) булып торалар. Калган икесе - әлеге тезисларны дәлилләү өчен хезмәт итә ала торган фактлар. Тиешле җөмләләрнең номерларын таблицага язып куегыз.
1) Иван IV идарә итү вакытында Россия көнчыгышта актив тышкы сәясәт алып барган.
2) Иван IV алып барган опричнина сәясәте ил өчен һәлакәтле булган.

3) Россиянең күп кенә үзәк өязләре бөлгенлеккә төшкән.
4) Рус гаскәрләре Казанны алган.

| Түбәндәгеләрне эченә алган җөмләләрнең номерлары | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тезис 1 | факт 1 | тезис 2 | факт 2 |
| җавап: | | | | |

7 Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*Россия икътисадына төрле илләрнең инвестицияләре*

| Ел | Франция | Англия | Германия |
|---|---|---|---|
| 1880 | 31,4 млн сум | 30,1 млн сум | 29,8 млн сум |
| 1890 | 66,6 млн сум | 35,3 млн сум | 79,0 млн сум |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** Әлеге таблица буенча 1890 елга Россия икътисадында өстенлек итә

**Б)** Әлеге таблица буенча XIX гасыр ахырына Россия икътисадына чит ил инвестицияләре

**В)** Әлеге таблица буенча XIX гасыр ахырында аеруча көчсез динамика белән характерланган

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** арткан

**2)** Германия инвестицияләре

**3)** Англия инвестицияләре

**4)** Франция инвестицияләре

**5)** кимегән


Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

Җавап:

| А | Б | В |
|---|---|---|
| | | |



*Схеманы карагыз һәм 8-10 биремнәрне үтәгез*




8 Схемада күрсәтелгән вакыйгаларның ничәнче гасырда булуын күрсәтегез. Җавапны сүз белән языгыз.

Җавап: ______________________________.

9 Схема легендасында «5» цифры белән күрсәтелгән походның гаскәр башлыгын атагыз.
Җавап: ____________________________.

10 Тарихчы язмасыннан өзекне укыгыз. Өзектә шәһәрнең исеме төшеп калган, ә схемада ул шәһәр цифр белән күрсәтелгән. Шул цифрны языгыз.
“Мәскәү кенәзе барысын да рус җире өчен башын салырга чакырды. Җыелу урыны итеп ____________________ шәһәре сайланды. 25 августта бөек Мәскәү кенәзе шушы шәһәргә килде. Аны Мәскәү елгасы кушылдыгы Северки буенда, каршы алдылар. Икенче көнне иртән барлык воеводаларга гаскәр белән шәһәр читендәге Девичье кырына чыгарга кушылды. Монда поход алдыннан рус

**18** Санап кителгәннәрнең кайсысы Россиядә 1860-1870нче еллардагы Бөек реформалар үткәрелә башлауның бер сәбәбе (алшартлары) булып торган?
- рус-япон сугышының уңышсыз тәмамлануы
- Д.В.Каракозовның Александр Икенчегә һөҗүм итүе
- Россиянең Кырым сугышында уңышсызлыклары
- “Народная воля” оешмасы төзелү

Сез сайлаган нигезләмәнең 1860-1870нче елларда Россиядә Бөек реформалар үткәрелә башлау белән ничек бәйле булуын аңлатыгыз.

**19** Ике факт хаталы булган текстны укып чыгыгыз.
Николай I идарә иткәндә идеология мәсьәләсенә зур игътибар бирелгән. Халык мәгарифе министры граф С.С. Уваров рәсми сәясәтнең төп юнәлешен билгеләргә тиеш булган «православие, демократия, халык» дигән формула эшләгән. Илнең иҗтимагый тормышы бу вакытта төрле түгәрәкләр булуы белән характерланган. Бу түгәрәкләрдә төп рольне Россия язмышы һәм аның тарихи перспективалары турында бәхәсләшкән декабристлар һәм славянофиллар уйнаган.

Факт хаталарын табыгыз һәм аларны төзәтегез. Җавапларны түбәндәгечә күрсәтегез (таблицаның ике баганасын да тутырыгыз).

| Текстның хаталы нигезләмәсе | Текстның тикшерелгән нигезләмәсе |
|---|---|
| 1) | |
| 2) | |

**20** Гомуми уртак билгеләр булуга карамастан, С.Т. Разин һәм Е.И.Пугачев җитәкчелегендәге халык восстаниеләре арасында аермалар да булган дигән фикер яши. Шушы аермаларны раслаган кимендә ике фактны китерегез.

**21** Булачак танылган язучы, Одессадан гимназист, тарихка "кухарка балалары турында" циркуляр дигән исем белән кереп калган документ басылып чыкканнан соң, гимназиянең бишенче сыйныфыннан куып чыгарыла. Автобиографик повестенда язганча, моңа аның «чыгышы түбән булуы» сәбәп булган.
1. Югарыда телгә алынган циркуляр басылып чыккан вакытта идарә иткән императорны атагыз.
2. Шушы император идарә иткән чорда аның әтисе уздыра башлаган үзгәртеп коруларны яңадан торгызуга юнәлдерелгән сәясәтнең исемен күрсәтегез.
3. Хөкүмәт фикеренчә, ни өчен “түбән чыгышлы” балалар гимназиядә белем алырга тиеш булмаганнар?






Җавап:______________________________

**Мәдәни һәйкәлләр исемлеге һәм сурәтләре белән танышыгыз, 13 һәм 14 биремнәрен үтәгез.**

1) "Өч диңгез артына сәяхәт" («Хожение за три моря»);

2) "Бөек Мәскәү кенәзе турындагы тарих" (“История о великом князе Московском»;

3) “Канун һәм игелек турында сүз" («Слово о законе и благодати»)

4)



5)



13 Күрсәтелгән мәдәни һәйкәлләрнең кайсылары XVI гасырда иҗат ителгән. Ике мәдәни һәйкәлне сайлагыз һәм алар күрсәтелгән саннарны таблицага язып куегыз.

Җавап:

| | |
|---|---|
| | |

14 Күрсәтелгән мәдәни һәйкәлләрнең кайсысын митрополит Иларион иҗат иткән? Әлеге мәдәни һәйкәлнең тәртип номерын языгыз.

Җавап:

**!** ***Барлык җавапларыгызны 1 нче номерлы җаваплар бланкына, эшне башкару буенча бирелгән инструкциягә нигезләнеп, күчерергә онытмагыз.***
***Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## 2 нче бүлек

*Бу бүлектәге биремнәргә (15-21) җавапларны язу өчен 2 нче номерлы* **ЖАВАПЛАР БЛАНКЫН** *кулланыгыз. Башта биремнәрнең номерын (15, 16 һ. б.) языгыз, аннан соң аларга киңәйтелгән җавап бирегез. Җавапларны төгәл һәм аңлаешлы итеп языгыз.*



***Тарихи чыганактан өзек укыгыз һәм 15-17 биремнәрне үтәгез. Җавапларда текстагы мәгълүматны һәм тарих курсыннан алган белемнәрегезне кулланыгыз.***

Елъязмадан өзек укыгыз.

“Ул елны дружина Игорьга әйтте: “Свенельд уллары корал һәм киемсалымга төренгән, ә без ялангач. Әйдә, кенәз, бергәләп ясак җыярга барыйк, сиңа дә булыр, безгә дә”. Игорь аларның сүзен тыңлады һәм древляннардан ясак җыярга китте. Элеккеге ясакка тагын яңасын өстәде. Аның гаскәре древляннарны аяусыз кыйнады. Ясак җыеп, үз калаларына кайтырга чыктылар. Кайтып барганда, Игорь уйланды һәм дружинасына әйтте: ”Җыйган ясак белән өегезгә кайта торыгыз, ә мин кире борылам”. Ул гаскәрен өйгә кайтарып җибәрде, ә үзе, зур байлык теләп, кече дружинасы белән кире китте. Древляннар бу турыда ишетеп, кенәз Мал янына киңәшкә килделәр: “Бүре сарыкларны алып китәсе килсә, бөтен көтүне буып бетергәнче тырышачак; бу да шулай: әгәр аны үтермәсәк, безне харап итәчәк”. Аңа каршы җибәрделәр: “Ник яңадан киләсең? Бөтен ясакны җыеп бетердең бит!” Игорь аларны тыңламады. Древляннар Искоростень шәһәреннән чыгып, Игорьне һәм дружиначыларын үтерделәр. Алар бик аз иде бит...

Ольга ул вакытта ________________ исемле улы белән Киевта иде. Древляннар әйттеләр: “Менә без рус кенәзен үтердек, хатыны Ольганы, аның улын үзебезнең кенәз Малга алабыз, алар белән нәрсә эшлисебез килә, шуны эшлибез”...”

15 Тасвирланган вакыйгаларның ничәнче гасырда булуын күрсәтегез. Текстта төшеп калган исемне языгыз.

16 Елъязма буенча ни өчен древляннар кенәз Игорьны үтерергә булганнар? Елъязма буенча ни өчен древляннар кенәз Игорьның дружинасын җиңә алганнар?

17 Тасвирланган вакыйгаларның теләсә нинди бер нәтиҗәсен күрсәтегез. Киев кенәзе Владимир тарафыннан дин сайлауга йогынты ясаган нинди гамәл текстта телгә алынган Ольга тарафыннан башкарылган?

***18-21 биремнәр тарихи материал белән төрле төрдәге эш башкаруны күз алдында тота: сәбәп-максат бәйләнешләрен билгеләү (18), тарихи текстка анализ, андагы хаталарны табу һәм төзәтү (19), тарихи вакыйгаларны һәм күренешләрне чагыштыру (20), тарихи шәхес эшчәнлеге белән бәйле тарихи ситуациягә анализ (21). Бу биремнәрне башкарганда, һәр сорауның формулировкасына игътибар итегез.***

- рус-япон сугышының уңышсыз тәмамлануы
- Д.В.Каракозовның Александр Икенчегә һөҗүм итүе
- Россиянең Кырым сугышында уңышсызлыклары
- “Народная воля” оешмасы төзелү

Сез сайлаган нигезләмәнең 1860-1870нче елларда Россиядә Бөек реформалар үткәрелә башлау белән ничек бәйле булуын аңлатыгыз.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавап түбәндәге элементлардан торырга тиеш:<br>1) дөрес җавап – Россиянең Кырым сугышында уңышсызлыклары;<br>2) аңлату, мәсәлән: Россиянең Кырым сугышында җиңелүе аның иң көчле Европа державаларыннан икътисади яктан калышуына күрсәтте. Бу артта калуның сәбәбе булып эшче көчләр җитмәүне тудырган, хезмәт нәтиҗәлелеген күтәрүгә комачаулаган, шуның белән сәнәгатьнең үсешен тоткарлаган крепостнойлык хокукы торды. Кырым сугышында җиңелү идарә итүчеләрдә крепостнойлык хокукын бетерү теләген барлыкка китерде, ә бу, үз чиратында, башка реформалар үткәрүне таләп итте.<br>(Башка, мәгънәсе буенча охшаш аңлату булырга мөмкин) | |
| Дөрес җавап һәм дөрес аңлату бирелгән. | 2 |
| Дөрес җавап бирелгән, аңлату бирелмәгән.<br>ЯКИ Дөрес җавап бирелгән, аңлату дөрес түгел | 1 |
| Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | 2 |

19 Ике факт хаталы текстны укып чыгыгыз.

Николай I идарә иткәндә идеология мәсьәләсенә зур игътибар бирелгән. Халык мәгарифе министры граф С.С. Уваров рәсми сәясәтнең төп юнәлешен билгеләргә тиеш булган «православие, демократия, халык» дигән формула эшләгән. Илнең иҗтимагый тормышы бу вакытта төрле түгәрәкләр булуы белән характерланган. Бу түгәрәкләрдә төп рольне Россия язмышы һәм аның тарихи перспективалары турында бәхәсләшкән декабристлар һәм славянофиллар уйнаган.

Факт хаталарын табыгыз һәм аларны төзәтегез. Җавапларны түбәндәгечә күрсәтегез (таблицаның ике баганасын да тутырыгыз).

| Текстта хата киткән урын | Текстның төзәтелгән урыны |
|---|---|



*Һәр җавапның биремнең дөрес номеры янында язылуын тикшерегез.*

**Тарихтан имтихан эшен бәяләү системасы**

**1 нче бүлек**

2, 3, 5, 6, 8-12, 14 биремнәрнең һәркайсына тулы дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә; тулы, дөрес булмаган җавап яки җавап булмаса - 0 балл.

1, 4, 7, 13 биремнәренә тулы дөрес җавап 2 балл белән бәяләнә; әгәр бер хата җибәрелсә - 1 балл; әгәр ике хата җибәрелсә яки җавап булмаса - 0 балл.

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 153 |
| 2 | 2431 |
| 3 | рекрутлар |
| 4 | 34 |
| 5 | 4 |
| 6 | 1423 |
| 7 | 213 |
| 8 | ундүртенче |
| 9 | Мамай |
| 10 | 2 |
| 11 | 1 |
| 12 | Пестель |
| 13 | 25 |
| 14 | 3 |

**2 нче бүлек**

**Киңәйтелгән җаваплы биремнәрнең үтәлешен бәяләү критерийлары**

2 өлешнең биремнәре җавапның тулылыгына һәм дөреслегенә карап бәяләнә. 15-18 һәм 20 биремнәргә җаваплар өчен 0 дән 2 баллга кадәр куела. 19 һәм 21 биремнәрне үтәгән өчен 0 дән 3 баллга кадәр куелырга мөмкин.

Елъязмадан өзек укыгыз.

“Ул елны дружина Игорьга әйтте: “Свенельд уллары корал һәм киемсалымга төренгән, ә без ялангач. Әйдә, кенәз, бергәләп ясак җыярга барыйк, сиңа дә булыр, безгә дә”. Игорь аларның сүзен тыңлады һәм древляннардан ясак җыярга китте. Элеккеге ясакка тагын яңасын өстәде. Аның гаскәре древляннарны аяусыз кыйнады. Ясак җыеп, үз калаларына кайтырга чыктылар. Кайтып барганда, Игорь уйланды һәм дружинасына әйтте: ”Җыйган ясак белән өегезгә кайта торыгыз, ә мин кире борылам”. Ул гаскәрен өйгә кайтарып җибәрде, ә үзе, зур байлык теләп, кече дружинасы белән кире китте. Древляннар бу турыда ишетеп, кенәз Мал янына киңәшкә килделәр: “Бүре сарыкларны алып китәсе килсә, бөтен көтүне буып бетергәнче тырышачак; бу да шулай: әгәр аны үтермәсәк, безне харап итәчәк”. Аңа каршы җибәрделәр: “Ник яңадан киләсең? Бөтен ясакны җыеп бетердең бит!” Игорь аларны тыңламады. Древляннар Искоростень шәһәреннән чыгып, Игорьне һәм дружиначыларны үтерделәр. Алар бик аз иде бит...

Ольга ул вакытта исемле улы белән Киевта иде. Древляннар әйттеләр: “Менә без рус кенәзен үтердек, аның хатыны Ольганы, аның улын үзебезнең кенәз Малга алабыз, алар белән нәрсә эшлисебез килә, шуны эшлибез”...”

**15** Тасвирланган вакыйгаларның кайчан булуын күрсәтегез. Текстта төшеп калган исемне языгыз.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавап түбәндәге <u>элементлардан</u> торырга тиеш:<br>1) <u>гасыр</u> – X г.;<br>2) <u>исем</u> – Святослав.<br><br>Һәр элемент дөрес позицияләр янында ялгыш позицияләр булмаган очракта гына исәпләнергә мөмкин | |
| Гасыр һәм исем дөрес күрсәтелгән | 2 |
| Гасыр гына дөрес күрсәтелгән.<br>ЯКИ Исем генә дөрес күрсәтелгән | 1 |
| Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | 2 |

**16** Елъязма нигезендә ни өчен древляннар кенәз Игорьны үтерергә булганнар? Елъязма нигезендә ни өчен древляннар кенәз Игорьның дружинасын җиңә алганнар?

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавап түбәндәге <u>элементлардан</u> торырга тиеш:<br>1) <u>беренче сорауга җавап</u>: кенәз Игорь древляннардан кабат ясак җыярга була (“Бүре сарыкларны алып китәсе килсә, бөтен көтүне буып бетергәнче тырышачак; бу да шулай: әгәр аны үтермәсәк, безне харап итәчәк”);<br>2) <u>икенче сорауга җавап</u>: кенәз Игорьның гаскәре (дружиначылар) аз санлы була | |
| Ике сорауга дөрес җавап бирелгән | 2 |
| Бер сорауга дөрес җавап бирелгән | 1 |
| Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | 2 |



**17** Тасвирланган вакыйгаларның теләсә нинди бер нәтиҗәсен күрсәтегез. Киев кенәзе Владимир тарафыннан дин сайлауга йогынты ясаган нинди гамәлне текстта телгә алынган Ольга башкарган?

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавап түбәндәге <u>элементлардан</u> торырга тиеш:<br>1) <u>нәтиҗә</u>, мәсәлән:<br>- кенәз Ольганың древляннарга үче;<br>- дәресләр һәм погостлар билгеләү;<br>(Башка нәтиҗә күрсәтелергә мөмкин.)<br>2) <u>гамәл</u> – кенәз Ольганың христианлык кабул итүе | |
| Нәтиҗә һәм гамәл дөрес күрсәтелгән | 2 |
| Теләсә кайсы бер элемент дөрес күрсәтелгән | 1 |
| Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | 2 |

**18** Санап кителгәннәрнең кайсысы Россиядә 1860-1870нче еллардагы Бөек реформалар үткәрелә башлауның бер сәбәбе (алшартлары) булып торган?

| | | |
|---|---|---|
| 1) | | |
| 2) | | |
| | | |

3) Е.И. Пугачев җитәкчелегендәге восстаниедә тау заводы эшчеләре катнашкан, ә С.Т. Разин җитәкчелегендәге восстаниедә - юк;

4) Е.И. Пугачев җитәкчелегендәге восстание катнашучылар саны һәм территорияне колачлау буенча масштаблырак булган.

Башка аермалар китерелергә мөмкин.

| | |
|---|---|
| Ике аерма дөрес күрсәтелгән | 2 |
| Бер генә аерма дөрес күрсәтелгән | 1 |
| Бирем таләпләренә туры килми торган гомуми характердагы фикерләр китерелгән. ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | 2 |

| Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар рөхсәт ителә) | Баллар |
|---|---|
| Дөрес җавапта түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш. | |
| **Текстта хата киткән урын** / **Текстның төзәтелгән урыны** | |
| 1) Халык мәгарифе министры граф С.С. Уваров рәсми сәясәтнең төп юнәлешен билгеләргә тиеш булган «православие, *демократия*, халык» дигән формула эшләгән. / Халык мәгарифе министры граф С.С. Уваров рәсми сәясәтнең төп юнәлешен билгеләргә тиеш булган «православие, *самодержавие*, халык» дигән формула эшләгән. | |
| 2) Бу түгәрәкләрдә төп рольне Россия язмышы һәм аның тарихи перспективалары турында бәхәсләшкән *декабристлар* һәм славянофиллар уйнаган. / Бу түгәрәкләрдә төп рольне Россия язмышы һәм аның тарихи перспективалары турында бәхәсләшкән *көнбатышчылар* һәм славянофиллар уйнаган. | |
| Ике хаталы урын дөрес күрсәтелгән, ике төзәтү дөрес эшләнгән | 3 |
| Бер-ике хаталы урын дөрес күрсәтелгән, бер төзәтмә дөрес ясалган | 2 |
| Ике хаталы урын гына дөрес күрсәтелгән, төзәтүләр дөрес ясалмаган. ЯКИ Ике хаталы урын гына дөрес күрсәтелгән, төзәтүләр ясалмаган. | 1 |
| Бер хаталы урын гына дөрес күрсәтелгән, төзәтүләр дөрес ясалмаган. ЯКИ Бер хаталы урын гына дөрес күрсәтелгән, төзәтүләр ясалмаган. ЯКИ Хаталы урыннар күрсәтелмәгән, төзәтүләр бар (ничәү булса да) ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | 3 |

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавап түбәндәге элементлардан торырга тиеш: 1) дөрес җавап – Россиянең Кырым сугышында уңышсызлыклары; 2) аңлату, мәсәлән: Россиянең Кырым сугышында җиңелүе аның иң көчле Европа державасыннан икътисади яктан калышуына күрсәтте. Бу артта калуның сәбәбе булып эшче көчләр җитмәүне тудырган, күтәрүгә комачаулаган, шуның белән сәнәгатьнең үсешен тоткарлаган, крепостнойлык хокукы торды. Кырым сугышында җиңелү идарә итүчеләрдә крепостнойлык хокукын бетерү теләген барлыкка китерде, ә бу, үз чиратында, башка реформалар үткәрүне таләп итте. (Башка, мәгънәсе буенча охшаш аңлату булырга мөмкин) | |
| Дөрес җавап һәм дөрес аңлату бирелгән. | 2 |
| Дөрес җавап бирелгән, аңлату бирелмәгән. ЯКИ Дөрес җавап бирелгән, аңлату дөрес түгел | 1 |
| Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | 2 |

| аааа20. Гомуми уртак билгеләр булуга карамастан, С.Т. Разин һәм Е.И.Пугачев җитәкчелегендәге халык восстаниеләре арасында аерымлыклар да булган дигән фикер яши. Шушы аермаларны исбатлаган кимендә ике фактка мисал китерегез. | **Баллы** |
|---|---|
| **20. Гомуми уртак билгеләр булуга карамастан, С.Т. Разин һәм Е.И.Пугачев җитәкчелегендәге халык восстаниеләре арасында аерымлыклар да булган дигән фикер яши. Шушы аермаларны исбатлаган кимендә ике фактка мисал китерегез.Содержание верного ответа и указания по** | |

Гомуми уртак билгеләр булуга карамастан, С.Т. Разин һәм Е.И.Пугачев җитәкчелегендәге халык восстаниеләре арасында аермалар да булган дигән фикер яши. Кимендә ике аерманы китерегез.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Түбәндәге аермалар күрсәтелергә мөмкин:<br>1) Е.И. Пугачев, С.Т. Разиннан аермалы буларак, үзен патша итеп күрсәткән (император Петр III);<br>2) Е.И. Пугачев, С.Т. Разиннан аермалы буларак, Россия империясенең дәүләт атрибутларын (Хәрби коллегия, якыннар өчен граф титуллары һ.б.) да алган.<br>3) Е.И. Пугачев җитәкчелегендәге восстаниедә тау заводы эшчеләре катнашкан, ә С.Т. Разин җитәкчелегендәге восстаниедә - юк;<br>4) Е.И. Пугачев җитәкчелегендәге восстание катнашучылар саны һәм территорияне колачлау буенча масштаблырак булган.<br>Башка аермалар китерелергә мөмкин | |
| Ике аерма дөрес күрсәтелгән | 2 |
| Бер генә аерма дөрес күрсәтелгән | 1 |
| Бирем таләпләренә туры килми торган гомуми характердагы фикерләр китерелгән.<br>ЯКИ<br>Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | 2 |

21 Булачак танылган язучы, Одессадан гимназист, тарихка "кухарка балалары турында" циркуляр дигән исем белән кереп калган документ басылып чыкканнан соң, гимназиянең бишенче классыннан куып чыгарыла. Автобиографик повестенда язганча, моңа аның «чыгышы түбән булуы» сәбәп булган.

1. Югарыда телгә алынган циркуляр басылып чыккан вакытта идарә иткән императорны атагыз.
2. Шушы император идарә иткән чорда аның этисе уздыра башлаган үзгәртеп коруларны яңадан торгызуга юнәлдерелгән сәясәтнең исемен күрсәтегез.
3. Хөкүмәт фикеренчә, "түбән чыгышлы" балалар ни өчен гимназиядә белем алырга тиеш булмаганнар?



| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавап түбәндәге элементлардан торырга тиеш:<br>1) император – Александр III;<br>2) сәясәтнең исеме - контрреформалар (консерватив курс);<br>3) сәбәп: хөкүмәт революцион хәрәкәтнең төп хәрәкәт көче булып студентлар һәм "түбән катламнардан" чыккан белемле кешеләр тора дип исәпләгән һәм "кухарка балалары турында" циркуляр ярдәмендә "түбән катлам" вәкилләренә студентлар булу мөмкинлекләрен тоткарларга омтылган | |
| Император, сәясәтнең исеме һәм сәбәп дөрес күрсәтелгән | 3 |
| Теләсә кайсы ике элемент дөрес күрсәтелгән | 2 |
| Теләсә кайсы бер элемент дөрес күрсәтелгән | 1 |
| Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | 3 |

Төп гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибе нигезендә (Россия Мәгариф министрлыгы һәм Рособрнадзорның 07.11.2018 № 189/1513 боерыгы, Россия Юстиция министрлыгы тарафыннан 10.12.2018 № 52953 теркәлгән.)

«64. Имтихан эшләре ике эксперт тарафыннан тикшерелә. Экспертлар бер-берсеннән бәйсез рәвештә тикшерү нәтиҗәләре буенча имтихан эше биремнәренә һәр җавап өчен баллар куялар... Ике эксперт куйган балларда сизелерлек аерма булган очракта, өченче тикшерү билгеләнә. Баллардагы сизелерлек аерма тиешле уку предметы буенча бәяләү критерийларында билгеләнгән.

Имтихан эшен тикшермәгән экспертлардан өченче эксперт предмет комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләнә.

Өченче экспертка укучының имтихан эшен тикшергән экспертлар тарафыннан куелган баллар турында мәгълүмат бирелә. Өченче эксперт куйган баллар ахыргы булып тора».

| | |
|---|---|
| 2) Общественная жизнь страны в это время характеризовалась наличием различных кружков, где главную роль играли так называемые *декабристы* и славянофилы | Общественная жизнь страны в это время характеризовалась наличием различных кружков, где главную роль играли так называемые *западники* и славянофилы |